Чыганак: Миңнуллин, Ф. Балта явызлар кулында: әдәби тәнкыйть мәкаләләре / Ф. Миңнуллин.- Казан: Татар. кит. нәшр., 1994.- 344 б.

# *Нәби Дәүли*

Танылган язучыбыз Нәби Дәүлинең 50 яшенә карата кечкенә бер мәкалә язарга булгач, аның барлык җыентыкларын тагын бер мәртәбә күздән кичерергә туры килде. Минем алда уннарча китап: «Бәхет» (1937), «Ал чәчәк» (1939), «Уйлар» (1940), «Кырык шигырь» (1941), «Иртәнге җыр» (1955), «Юлда» (1957) һ. б. Аларда шагыйрьнең утыз еллык иҗаты. Матур-матур шигырьләр, поэмалар, җырлар, әдәби парчалар, пародияләр...

Шагыйрьне тормышыбызның күп күренешләре иҗатка рухландырган, күп нәрсәләр борчыган. Ул хезмәт, батырлык, туган ил, яшьлек, мәхәббәт турында җырлый. Хәер, аларның барын да бер мәкаләдә санап чыгарга мөмкинмени?!. Шулай да, Нәби Дәүли иҗатының асылы нидә, ул нәрсә турында күбрәк яза? — дип конкрет сорау куйсалар:

— Нәби Дәүли иҗаты — Ватан һәм аңа лаеклы булу турында,— дип әйтер идек.

Бәхетлеме кеше дөньяда?
Ят илләрдә рәхәт торса да,
Болытларга кадәр җиткереп
Асыл таштан сарай корса да,
Туган йортын кабат күрмәсә,
Туган җиргә ятып үлмәсә,
Яз көнендә чәчәк куярга
Каберенә дуслар килмәсә,
Бәхетлеме кеше дөньяда? —

ди ул бер шигырендә.

Дөньяда иң зур бәхет — үз илендә, туган туфрагында ятып үлү икән. Бу юлларда шагыйрьнең туган җирне сөюе, аңа чиксез мәхәббәте иң югары ноктасына күтәрелгән, аның Ватан турындагы уй-фикерләре бер фокуска җыеп бирелгән. Шагыйрьнең бу сүзләрендә зур хаклык бар. Ә Нәби Дәүлинең үзе өчен — бигрәк тә...

Сабый чакта ук ятим калган Нәби җиде яшендә Кавказдагы татар байларының берсендә мал-туар көтә, соңга таба байның туганнарына батраклыкка яллана. Яңа хуҗасы аны урамга куып чыгара. Яңа власть ятим малайны балалар йортына урнаштыра, киендерә, тәрбияли...

Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтка киткән шагыйрь, авыр яралы хәлдә, әсирлеккә эләгә, фашизмның єрткычлыгын үз җилкәсендә татый. Аның бөтен уйлары Ватан турында була...

Менә шуның өчен дә бу шагыйрьнең: «Туган ил туфрагына ятып үлү — иң зур бәхет» дип әйтергә хакы бар.

Нәби Дәүлинең шигырьләрен яраталар һәм укыйлар. Ул иҗатының тормышчан булуы белән, чын йөрәктән җырлавы белән укучылар мәхәббәтен казанды.

Нәби Дәүли тудырган матур образлар, аның үзенчәлекле шигъри алымнары, формалары бар. Менә бер генә мисал:

Атакага барган чакта
Солдат егылды.
Йөрәге аның суынды,
Ә җир җылынды.

Бу — аның «Солдат турында поэма»сы. Нибары дүрт юл. Шушы дүрт юлга шагыйрь нинди зур мәгънә салган! Шушы дүрт юлда никадәр фикер, никадәр шигърият!

Нәби Дәүли үзенең илле яшен зур иҗат планнары белән каршылый. Соңгы елларда гына да ул бик күп яңа шигырьләр, поэмалар язды. 1957 елда Татарстан китап нәшрияты совет солдатларының фашизм тоткынлыгында күргән газаплары, аларның Ватанга турылыклы булулары турында «Яшәү белән үлем арасында» исемле китап бастырып чыгарды. Фашизмга көчле нәфрәт, шигъри тел белән язылган бу әсәрне укучы җылы каршылады. 1959 елда «Яшәү белән үлем арасында» зур тираж белән икенче мәртәбә басылды. Якын көннәрдә Нәби Дәүлинең бу китабы рус телендә чыгачак.

Татар дәүләт курчак театрында аның «Каракаш батыр» пьесасы уңыш белән бара. Газета-журналларда бүгенге көн турында шигырьләре, поэмалары басыла. Татарстан китап нәшрияты шагыйрьнең сайланма әсәрләрен хәзерли...

*1960*